КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 13 сентябрь г.Казань № 6-2072

Урманга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан урманнарны саклау һәм торгызу мәсьәләләренә карата җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатларында, шулай ук 2025 елда Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын үткәрү кысаларында:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

2025 елның 4 октябреннән 11 октябренә кадәр урман фонды территориясендә «Урманны саклап калыйк» дигән табигатьне саклау акциясен (алга таба – Акция) үткәрүне оештырырга;

тиешле эшләрне башлап җибәрү алдыннан хезмәт иминлеге буенча максатчан инструктажны мәҗбүри үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Республика башкарма хакимият органнарына Акциядә катнашырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә Акция үткәрүне оештыруны һәм анда катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Акцияне яктыртуны, шулай ук урманга карата сакчыл мөнәсәбәт турында материаллар бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин